ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасында янгыннан ирекле саклау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 487-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты А.А. Чубаров тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасында янгыннан ирекле саклау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 487-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ
АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре,
2023 елның 2 ноябре
№ 2211-VI ДС

Проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутаты
А.А. Чубаров тарафыннан
кертелә

**«Татарстан Республикасында янгыннан ирекле саклау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында»**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

**1 статья**

«Татарстан Республикасында янгыннан ирекле саклау турында» 2011 елның 1 августындагы 48-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2011, № 8 (I өлеш); 2014, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 55 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«1 статья. **Әлеге Законны куллану өлкәсе**

Әлеге Законның гамәлдә булуы физик затлар һәм юридик затлар – иҗтимагый берләшмәләр тарафыннан Татарстан Республикасы территориясендә янгыннарны профилактикалауга һәм (яисә) сүндерүгә һәм һәлакәттән коткару эшләрен башкаруга бәйле янгыннан ирекле саклау эшчәнлегендә катнашу хокукын гамәлгә ашыруга бәйле рәвештә аларга кагыла.»;

2) 4 статьяда:
а) исемдә «иҗтимагый берләшмәләр» сүзләрен «янгыннан ирекле саклау иҗтимагый берләшмәләре» сүзләренә алмаштырырга;
б) «янгыннан ирекле саклау буенча иҗтимагый берләшмәләрнең» сүзләрен соң «янгыннан ирекле саклау иҗтимагый берләшмәләренең (алга таба – янгыннан саклау иҗтимагый берләшмәләре)» сүзләренә алмаштырырга;

3) 5 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«5 статья. **Янгыннан саклау иҗтимагый берләшмәләре мөлкәте**

Янгыннан саклау иҗтимагый берләшмәләре мөлкәте Россия Федерациясе законнары нигезендә башлангыч кертемнәр һәм әгъза буларак түләнә торган кертемнәр, әгәр аларны түләү тиешле янгыннан саклау иҗтимагый берләшмәсе уставында каралган булса, аны гамәлгә куючыларның кертемнәре, ихтыярый кертемнәр һәм иганәләр, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан Россия Федерациясе законнары, Татарстан Республикасы законнары, муниципаль хокукый актлар нигезендә янгыннан саклау

иҗтимагый берләшмәләренә күрсәтелә торган ярдәм чаралары исәбеннән әлеге уставка таянып үткәрелә торган чаралардан кертемнәр һәм Россия Федерациясе законнары белән тыелмаган башка кертемнәр (шул исәптән, янгыннан мөлкәтне һәм (яисә) граждан җаваплылыгын иминләштерүне гамәлгә ашыручы иминият оешмалары акчалары) нигезендә туплана.»;

4) 7 статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

5) 8 статьяда «Янгыннан ирекле саклау командалары (дружиналары)» сүзләрен «Ирекле янгын сүндерү бүлекчәләре» сүзләренә алмаштырырга;

6) 9 статьяның 1 пунктында «янгыннан саклау буенча иҗтимагый берләшмәләр хезмәткәрләрен һәм анда катнашырга теләүчеләрне» сүзләрен «ирекле янгын сүндерүчеләрне һәм янгыннан саклау иҗтимагый берләшмәләренең янгыннан ирекле саклау хезмәткәрләрен» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон 2024 елның 1 февраленнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасында янгыннан ирекле саклау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законы проектына аңлатма**

«Татарстан Республикасында янгыннан ирекле саклау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты Татарстан Республикасы норматив хокукый базасын федераль законнарга кертелгән үзгәрешләргә туры китерү максатларында эшләнде.

«Янгыннан ирекле саклау турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 4 августындагы 445-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – Федераль закон) белән «Янгыннан ирекле саклау турында» 2011 елның 6 маендагы 100-ФЗ номерлы Федераль законга оешмалардагы янгын куркынычсызлыгы системасының нәтиҗәлелеген арттыруга юнәлдерелгән үзгәрешләр кертелде.

Федераль закон белән «Янгыннан ирекле саклау турында» Федераль законның төшенчәләр аппаратына «ирекле янгын сүндерү бүлекчәсе», «территориаль ирекле янгын сүндерү бүлекчәсе», «объекттагы ирекле янгын сүндерү бүлекчәсе» билгеләмәләре өстәлде, шулай ук төрле милек рәвешләрендәге оешмаларга, янгыннан саклау иҗтимагый берләшмәсе төземичә генә, мөстәкыйль рәвештә ирекле янгын сүндерү бүлекчәләре төзү мөмкинлеге бирелде.

Федераль законнарга кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып, «Татарстан Республикасында янгыннан ирекле саклау турында» 2011 елның 1 августындагы 48-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына тиешле үзгәрешләрне кертү тәкъдим ителә.

Бу үзгәрешләр югарыда әйтелгән Законның 1, 4, 5, 8 һәм 9 статьяларына кагыла.

Моннан тыш, закон проекты белән барлык төр янгыннан саклау эшчәнлеген координацияләү янгынга каршы федераль хезмәткә йөкләнүгә бәйле рәвештә янгыннан ирекле саклау эшчәнлеген координацияләүне җайга салучы норманы (Законның 7 статьясы) төшереп калдыру тәкъдим ителә.

**«Татарстан Республикасында янгыннан иракле саклау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалтуы танылырга, туктатылып торырга, үзгәртелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы закон актлары исемлеге**

«Татарстан Республикасында янгыннан иракле саклау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы закон актларын үз көчләрен югалткан дип тану, туктатып тору, үзгәртү яисә кабул итү таләп ителми.

**«Татарстан Республикасында янгыннан ирекле саклау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына финанс-икътисадый нигезләү**

«Татарстан Республикасында янгыннан ирекле саклау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнар таләп итми.